# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

Татарстан Республикасының Дәүләт арбитражын
Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды
итеп үзгәртеп коруга бәйле рәвештә Татарстан
Республикасы Конституциясенә /Төп Законына/
үзгәрешләр һәм өстәмәләр турында

Татарстан Республикасының Дәүләт арбитражын Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды итеп үзгәртеп коруга бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Югары Советы КАРАР БИРӘ:

I. Татарстан Республикасы Конституциясенә /Төп Законына/ түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1. 92 маддәнең дүртенче өлешенең I4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"I4/ Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды Рәисен сайлау һәм эштән азат итү.

Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды Рәисенең беренче урынбасары, урынбасары, арбитраж коллегиясенең рәисләре, Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды әгъзалары Татарстан Республикасы Югары арбитраж судының Рәисе тәкъдиме буенча сайлана һәм эштән азат ителә".

2. 97 маддәдәге "Татарстан Республикасы Баш дәүләт арбитры" дигән сүзләрне "Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды" дигән сүзләр белән алмаштырырга".

3. I05 маддәнең 2 өлешендәге "шулай ук Татарстан Республикасының Дәүләт арбитражы коллегиясе" дигән сүзләрне "Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды" дигән сүзләр белән алмаштырырга, аннан соң тексттагыча.

4. I09$^{6}$ маддәнең 7 пунктының 2 абзацындагы "Татарстан Республикасының Баш дәүләт арбитры" дигән сүзләрне "Татарстан Республикасының Баш арбитраж суды Рәисе" дигән сүзләр белән алмаштырырга, аннан соң тексттагыча.

5. УШ кисәкнең исемендәге "арбитраж" сүзен төшереп калдырырга.

6. I5 бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Татарстан Республикасының суд системасы".

7. I40 матдәнең 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Татарстан Республикасының суд системасына түбәндәгеләр керә: Татарстан Республикасының Югары суды, Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды һәм район /шәһәр/ халык судлары".

8. I4I матдәнең 4 һәм 5 өлешләрен 5 һәм 6 өлеш итеп санарга.

9. I4I матдәгә түбәндәге эчтәлектә 4 өлеш өстәргә:

"Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды Татарстан Республикасы Югары Советы тарафыннан сайлана. Аның вәкаләтләре билгеле бер вакыт кысалары белән чикләнми".

I0. I4I матдәнең 5 өлешендә "бөтен судьялар" дигән сүзләрдән соң"башкаларны" дигән сүз өстәргә, аннан соң тексттагыча.

11. I45 матдәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Татарстан Республикасының Югары арбитраж суды - икътисади бәхәсләрне карау буенча Татарстан Республикасының югары суд органы. Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды рәистән, аның урынбасарларыннан һәм Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды әгъзаларыннан гыйбарәт".

П. Әлеге Закон кабул ителгән мизгеленнән гамәлгә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1992 елның 22 мае
№1516-XП